ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт: http://ojm.tatarstan.ru

**Приказ** **Казан шәһәре** **Боерык**

16.07.2024 № 193- од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 07 июнендәге 146-од боерыгы белән расланган Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәт срогын озайту белән бәйле рәвештә капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертүтурында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча эшне камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 07 июнендәге 146-од боерыгы белән расланган Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәт срогын озайту белән бәйле рәвештә капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган кушымта итеп

бирелгән үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 393-од номерлы, 2020 елның 27 апрелендәге 128-од номерлы, 2020 елның 05 ноябрендәге 339-од номерлы, 2021 елның30 апрелендәге 121-од номерлы, 2021 елның 31 августындагы 256-од номерлы, 2021 елның 27 сентябрендәге 292-од номерлы, 2022 елның31 мартындагы 73-од номерлы, 2022 елның 05 октябрендәге 354-од номерлы, 2023 елның 07 августындагы 227-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Р.Г. Шәрәфетдиновка йөкләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2024 елның 16 июлендәге 193-од номерлы боерыгы белән расланган

## Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 07 июнендәге 146-од боерыгы белән расланган Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәт срогын озайту белән бәйле рәвештә капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 нче бүлектә:

2.6.1 пунктының 2 пунктчасында:

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15) капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләүне территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта – территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә күчермәсе, ә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру шартнамә төземичә башкарылган очракта – территорияне комплекслы үстерү турындагы карарның күчермәсе. Шул ук вакытта, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын җәлеп итеп, комплекслы үстерергә тиешле территория чикләрендә капиталь төзелеш объектларын төзегән, реконструкцияләгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турындагы мондый шартнамәнең һәм (яисә) карарның күчермәләрен бирү таләп ителми.»;

2.6.2 пунктның 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15) капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләүне территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта – территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә күчермәсе, ә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру шартнамә төземичә башкарылган очракта – территорияне комплекслы үстерү турындагы карарның күчермәсе. Шул ук вакытта, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын җәлеп итеп, комплекслы үстерергә тиешле территория чикләрендә капиталь төзелеш объектларын төзегән, реконструкцияләгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турындагы мондый шартнамәнең һәм (яисә) карарның күчермәләрен бирү таләп ителми.»;

2.8 пунктының 1 пунктчасындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләүне җирле үзидарә органы тарафыннан территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория яисә аңа карата РФ ШтК 70 статьясы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта, территорияне планлаштыру буенча территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә нигезендә расланган документлар булмаганда (территорияне комплекслы үстерү турында карарны Татарстан Республикасы яки муниципаль берәмлек тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашыру яки мондый карарны РФ ГрК Татарстан Республикасы нигезендә билгеләнгән территорияне комплекслы үстерү операторы тарафыннан гамәлгә ашыру очракларыннан тыш).».